СОВЕТ КРИВООЗЕРСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АКСУБАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
423051, Аксубаевский район, с. Кривоозерки,
ул. Ленина, 9а, тел. 884344 4-43-45

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ КӘКРЕ КҮЛ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
423051 Аксубай районы, Кәкре Күл авылы ,
Ленина ур. 9а, тел. 884344 4-43-45
Krozer.Aks@tatar.ru

ИНН 1603001302 КПП 160301001 ОГРН 1061665002519 БИК 049205001 Р/С 40204810800000230005 ГРКЦ НБ РТ г.КАЗАНЬ

# КАРАР

2021 елның 04 июне № 25

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы
Кәкре күл авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында»
2019 елның 26 ноябрендәге 117 номерлы карарына
үзгәрешләр кертү хакында

РФ Салым кодексының 397 статьясындагы 1 өлеше нигезендә, Татарстан Республикасы Аксубай районы прокуратурасының 2021 елның 1 февралендәге 02-08-02 номерлы протестын үтәү йөзеннән һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга таянып, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Кәкре күл авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Кәкре күл авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында» 2019 елның 26 ноябрендәге 117 номерлы карарына түбәндәге өстәмәләрне һәм үзгәрешләрне кертергә:

1.1. «Салым һәм салым буенча аванс түләүләрен түләү тәртибе» 5 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Салым түләүче оешмалар өчен салым түләү җир кишәрлекләре урнашкан урын буенча җир кишәрлегенең кадастр бәясенең 1/4 процент өлешенең тиешле салым ставкасының 1/4 күләмендә аванс түләүләре белән башкарыла.»

2. Үз көчен югалткан дип танырга:

- Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Кәкре күл авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Кәкре күл авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында» 2019 елның 26 ноябрендәге 117 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2021 елның 12 апрелде 20 номерлы карары;

3. Әлеге карар Россия Федерациясе Салым кодексының 5 статьясы нигезендә үз көченә керә.

4. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә: http:// Aksubayevo.tatarstan.ru Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru 5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы
Кәкре Күл авыл җирлеге башлыгы, Совет рәисе С.С. Елисеев

СОВЕТ КРИВООЗЕРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ